**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

22.08.2023 № 280

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны премияләү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны премияләү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 1 июнендәге 152 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамада «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

текстта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны премияләү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия турындагы нигезләмәдә:

атамада «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны премияләү буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) – Татарстан Республикасы Рәисе каршында даими эшли торган коллегиаль орган. Комиссия әгъзалары җәмәгать башлангычларында эшли.

Комиссия Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны (алга таба – аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар) премияләү турындагы карарлар кабул итү максатларында төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына һәм

Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**